Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге
Шихазда торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

28 ноябрь, 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Шихазда торак пункты гражданнар җыенының 2021 елның 28 ноябрендәге йомгаклау беркетмәсе нигезендә карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 2 өлеше, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәнең 5 өлешендәге 5 пункты нигезендә түбәндәге мәсьәлә буенча түбәндәге карар кабул ителде:

«Сез, 2022 елда Шихазда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, Чернобыль АЭСын бетерү катнашучылары, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне, бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү»

**кабул ителмәгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесенен
вазыйфасын башкаручы П.В. Сиваев